КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 февраль г.Казань № 84

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең һәм «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең паллиатив медицина ярдәме бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен өстәмә акчалата түләүләр турында» 2015 ел, 10 апрель, 237 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең һәм «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең паллиатив медицина ярдәме бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен өстәмә акчалата түләүләр турында» 2015 ел, 10 апрель, 237 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 декабрь, 1131 нче, 2018 ел, 12 май, 347 нче, 2019 ел, 17 октябрь, 914 нче,

2020 ел, 13 июль, 585 нче, 2023 ел, 26 май, 640 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагындагы медицина оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары карамагындагы медицина оешмалары хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы буйсынуындагы аерым булмаган учреждениеләрнең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән» сүзләрен алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең һәм «Түбән Кама үзәк район күпюнәлешле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең паллиатив медицина ярдәме бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен өстәмә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру чыгымнарын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанс белән тәэмин итү тәртибендә:

2 пунктта:

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җиткерә.»;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык департаменты тарафыннан ачылган» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин